Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Кызыл Чапчак авыл җирлеге составына керүче Югары Чаллы торак пунктында

# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2023 елның 10 ноябре № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Кызыл Чапчак авыл җирлегенең Югары Чаллы торак пунктында граждannар җыены КАРАР БИРДЕ:

1. Түбән Кама муниципаль районының Кызыл Чапчак авыл җирлеге Югары Чаллы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм катнашучыларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарының тол хатыннарыннан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарның ире/хатыныннан, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, 2024 елда 3000 сум күләмендә үзара салым кертергә.
2. Алынган акчаларны:

– Советская урамына, Молодежная урамыннан зиратка кадәр юлны ремонтлауга;

– Чишмәне төзекләндерүгә, чишмәгә юл салуга;

– Парковая урамына, Тукай һәм Советская тыкрыгы юлын ремонтлауга юнәлдерергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Кызыл Чапчак авыл җирлеге башлыгы Б.В.Ильдарханов